Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кырынды торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**30 октябрь 2025 ел** **№ 1**

Гамәлдәге законнар нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына таянып, 2025 елның 30 октябрендә 13 сәгать 00 минутта, 30 октябрендә 15 сәгать 00 минутта, 30 октябрендә 17 сәгать 00 минутта “Әгерҗе муниципаль районының Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кырынды торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән (махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекледәр ) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан ( ата-аналар, ирләре яки хатыннары), I төркем инвалидлардан, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге ялгыз гражданнардан, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясенә хәрби хезмәткә чакырылган һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш), 2026 елда үзара салым акчасын 700 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны җирлек өчен әһәмияте булган мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне:

1. Торак пункт территориясен төзекләндерү (чүп үләннәрен чабу, юлларны кардан чистарту, тракторчыга хезмәт килешүе буенча түләү, тракторны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, Кырынды торак пунктында кеше тормышына куркыныч тудыручы авария хәлендәге һәм корыган агач-куакларны кисү, торак пункт территориясен әйләндереп алу өчен төзелеш материаллары сатып алу һәм төзекләндерү буенча башка чыгымнар);

2. Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау. Суга анализ ясаган өчен түләү, насослар сатып алу.

3. Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урамнарны яктырту өчен электр товарлары сатып алу, урнаштыру һәм алмаштыру; урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка чыгымнар);

4. Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча беренчел чаралар күрү (ягулык-майлау материаллары, янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу, хезмәт килешүе буенча янгын сүндерү машинасын йөртүчегә түләү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка чыгымнар).

башкаруга юнәлтүгә, куллануга ризамы?” дигән сорау буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

« РИЗА» «КАРШЫ»

Беркетмә нигезендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 343 катнашучы кертелде. Гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 175 кеше, бу 51% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенының 175 катнашучысы тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирүчеләр юк.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды :

1.Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кырынды торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Әгерҗе муниципаль районы « Кырынды авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кырынды торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән (махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекле хезмәткәрләр ) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (ата-аналары, ире яки хатыны), Iтөркем инвалидлардан, өлкән яшьтәге ялгыз гражданнардан (80 яшькә җиткәннәрдән), көндезге формада укучы студентлардан, Россия армиясе сафларына хезмәткә чакырылган һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш) 2026 елда үзара салым акчаларын 700 сум күләмендә кертергә.

3.Алынган акчаларны, җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:

1.Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Кырынды авылының Совет урамындагы юлларына вак таш сатып алу һәм салу; автомобиль юлларын карап тотуның башка чыгымнары).

2. Торак пункт территориясен төзекләндерү (чүп үләннәрен чабу, юлларны кардан чистарту, тракторчыга хезмәт килешүе буенча түләү, тракторны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, Кырынды торак пунктында кеше тормышына куркыныч тудыручы авария хәлендәге һәм корыган агач-куакларны кисү, торак пункт территориясен әйләндереп алу өчен төзелеш материаллары сатып алу һәм төзекләндерү буенча башка чыгымнар);

3. Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау. Суга анализ ясаган өчен түләү, насослар сатып алу.

4. Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урамнарны яктырту өчен электр товарлары сатып алу, урнаштыру һәм алмаштыру; урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка чыгымнар);

5. Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча беренчел чаралар күрү (ягулык-майлау материаллары, янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу, хезмәт килешүе буенча янгын сүндерү машинасын йөртүчегә түләү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка чыгымнар).

4. Карарны Кырынды авыл җирлегенең мәгълүмат стендында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы сайтында (https://agryz.tatarstan.ru), «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Авыл җирлеге башлыгы — Р.Р.Мәүликаев

Гражданнар җыенында рәислек итүче

авыл җирлеге башлыгы